**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2014 ел, 31 декабрь | № 1095

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе турында» 2012 ел, 2 октябрь, 818 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе уставына теркәлгән 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе турында» 2012 ел, 2 октябрь, 818 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 6 декабрь, 1061 нче; 2013 ел, 21 май, 335 нче; 2014 ел, 16 октябрь, 763 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе уставына теркәлгән 2 нче кушымтага, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе уставына 2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең аерымланган структур бүлекчәләре (институтлары һәм үзәкләре)

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәк белеме институты;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Перспективалы тикшеренүләр институты;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Гамәли семиотика институты;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Исламият гыйлеме үзәге;

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х.Халиков исемендәге Археология институты.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2014\1095.doc